**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О присуждении Государственных премий Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая в 2018 году

Рассмотрев предложения Комиссии при Президенте Республики Татарстан по Государственным премиям Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая, **постановляю**:

1. Присудить Государственные премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая:

1) Каримову Камилу Адгамовичу – за книги «Карурманда кара песи: повестьлар һәм хикәяләр», Татарское книжное издательство, Казань, 2015 год и «Игезәкләр йолдызлыгы: романнар», Татарское книжное издательство, Казань, 2016 год;

2) Кузнецову Михаилу Ивановичу – за серию работ «Белые холсты. Народы Поволжья»;

3) творческой группе публичного акционерного общества «Таттелеком» в составе Шафигуллина Лутфуллы Нурисламовича и Закуанова Рустама Газизяновича – за реализацию значимых проектов в сфере культуры и вклад в возрождение духовности, сохранение национальных ценностей и исторического наследия народов, проживающих в Республике Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
23 апреля 2018 года
№ УП-330

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2018 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Кәримов Камил Әдһәм улына – «Карурманда кара песи: повестьлар һәм хикәяләр», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2015 ел һәм «Игезәкләр йолдызлыгы: романнар», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2016 ел, китаплары өчен;

2) Кузнецов Михаил Ивановичка – «Ак киндерләр. Идел буе халыклары» эшләре сериясе өчен;

3) «Таттелеком» гавами акционер җәмгыятенең Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улыннан һәм Зәкуанов Рөстәм Газизҗан улыннан торган иҗат төркеменә – мәдәният өлкәсендәге әһәмиятле проектларны гамәлгә ашырган һәм рухиятне торгызуга, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли хәзинәләрен һәм тарихи мирасын саклап калуга өлеш керткән өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 23 апрель
№ ПУ-330